**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУЛЬБАЕВО-МАРАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛБАЙ-МОРАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Колбай-Мораса ав. **КАРАР**

№ 22 «04» октябрь 2021 ел

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында**

"Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнарның язма һәм телдән мөрәҗәгатьләрен карау һәм анализлау буенча бердәм тәртип урнаштыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән срокта бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту җаваплылыгын үз өстемә йөклим.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Колбай-Мораса авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ә. Насыйбуллин

Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 4 октябрендәге 22 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип "Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында" 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясын, "Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында" 2003 елның 12 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне анализлау, карау эшенең сыйфатын яхшырту, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм ысулларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауның сыйфатын арттыру максатларында уздырыла..

3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен анализлау тиешле чорда кергән барлык мөрәҗәгатьләр буенча, шул исәптән язма рәвештә дә, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү юлы белән электрон документ рәвешендә, шулай ук гражданнарны кабул итү барышында вәкаләтле затлар тарафыннан кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4. Ел саен кергән мөрәҗәгатьләргә анализ ясала.

5. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча киләсе хисап чорының 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзелә.

6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхсән күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат булырга тиеш (булганда).

7. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә тиешле вакыт эчендә узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән анализ үткәрелә.

8. Башкарма комитет сәркатибе ел саен аналитик белешмәне авыл җирлегенең рәсми сайтында "Гражданнар мөрәҗәгатьләре" бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.